ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОРОМАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422970, Республика Татарстан,
Чистопольский район, с.Старое Ромашкино,
ул.Центральная, 30 Б

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ РОМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422970, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Иске Роман авылы,
Центральная урамы, 30 Б

тел. 8(84342) 3 -10-13 E-mail: Strom.Ctp@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**2021 елның 12 мае** **№9**

Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитетының «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 17 мартындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан уңай икътисадый мохит булдыру максатларында, Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 17 мартындагы 1 номерлы карары белән расланган «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа паспортында «Чистай муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшкуарларның үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:
«Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |
| Барлыгы | 4» |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:
«5. Программаны финанслау:

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына методик, консультация-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук ярдәмнең финанс, мәгълүмати һәм башка рәвешләрен алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатында җирле бюджет акчалары исәбеннән түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сум)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1»; |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Р.Г. Дәүләтшина

Кушымта

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Иске Роман авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасы нәтиҗәләрен бәяләүнең максатлары һәм индикаторлары

| Төп чаралар исеме | Бурычка туры килү | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар билгеләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максат исеме: Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тәэмин итү, инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыру һәм аларның конкурентлык сәләтен тәэмин итү, шулай ук җирлекнең социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүгә аның өлешен арттыру | | | | | | | | |
| Республика һәм федераль бюджетлар акчаларыннан күрсәтелүче эшмәкәрлеккә ярдәм программалары буенча консультация ярдәме күрсәтү һәм мәгълүмат бирү | 3 | Чистай МР Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына күрсәтелгән консультацияләр саны, бер. | 3 | 3 | 3 | 3 |
| Кече урта эшкуарлыкны үстерү проблемаларына аларны хәл итү юлларын анкеталаштыру үткәрү | 4 | Чистай МР Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән анкеталар саны, бер. | 2 | 2 | 2 | 2 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Законнарны үзгәртү һәм үстерү, шулай ук эшкуарлыкка ярдәмнең гамәлдәге программалары буенча актуаль хокукый мәсьәләләр буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен киңәшмәләр һәм семинарлар үткәрү | 1 | Чистай МР Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән семинарлар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Аны яшьләр эшкуарлыгы өлкәсенә җәлеп итү буенча яшьләр бергәлеге белән эшләү | 2 | Чистай МР Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Чистай МР Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |